ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

09.02.2021 108а　　　　с. Верхний Услон　　　　________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2007нче елның 15нче маеннан 147нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, 2020нче елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021нче елның 4нче гыйнварындагы ПР-3нче номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2007нче елның 15нче маендагы 147нче номерлы карарының 1нче пунктына, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:
«Социаль ярдәм чаралары алучы мөрәҗәгать итүчеләрнең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, салымнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау».
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшеп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　　　　　И. И. Шакиров